ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ
ГОРОД НАБЕРЕЖНЫЕ ЧЕЛНЫ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЯР ЧАЛЛЫ ШӘҺӘРЕ
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

03 октябрь 2022 ел № 5189

Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегендә социаль юнәлешле коммерцияле булмаган оешмалар эшчәнлегенең финанс, икътисадый, социаль һәм башка күрсәткечләренә анализ үткәрү тәртибен раслау турында

«Коммерцияле булмаган оешмалар турында» 1996 елның 12 гыйнварындагы 7-ФЗ номерлы Федераль законның 31.3 статьясы нигезендә, социаль юнәлешле коммерцияле булмаган оешмаларның эшчәнлеге өчен шартлар тудыру максатында

К А Р А Р  Б И Р Ә М:

1. Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегендә социаль юнәлешле коммерцияле булмаган оешмалар эшчәнлегенең финанс, икътисадый, социаль һәм башка күрсәткечләренә анализ үткәрү тәртибен кушымтада каралганча расларга.

2. Башкарма комитетның эш кәгазьләрен алып бару идарәсенә әлеге карарны «Челнинские известия», «Шәһри Чаллы» газеталарында бастырып чыгаруны һәм аны «Интернет» челтәрендә Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (https://pravo.tatarstan.ru), Яр Чаллы шәһәренең рәсми сайтында (http://nabchelny.ru) урнаштыруны тәэмин итәргә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасары Н.А. Кропотовага, Башкарма комитетның җир һәм мөлкәти мөнәсәбәтләр идарәсе башлыгы Л.Р. Гыйззәтуллинга йөкләргә.

Башкарма комитет
Җитәкчесе Ф.Ш. Салахов

Башкарма комитетның
2022 елның 3 октябрендәге
5189 номерлы карарына
кушымта

Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегендә социаль юнәлешле коммерцияле булмаган оешмалар эшчәнлегенең финанс, икътисадый, социаль һәм башка күрсәткечләренә анализ үткәрү тәртибе

1 бүлек. Гомуми нигезләмәләр

1. Әлеге тәртип Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегендә социаль юнәлешле коммерцияле булмаган оешмалар (алга таба – СЮКБО) эшчәнлегенең финанс, икътисадый, социаль һәм башка күрсәткечләренә анализ үткәрү тәртибен билгели.

2. Әлеге Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегендә социаль юнәлешле коммерцияле булмаган оешмалар (алга таба – СЮКБО) эшчәнлегенең финанс, икътисадый, социаль һәм башка күрсәткечләренә анализ үткәрү тәртибендә (алга таба – Тәртип) файдаланыла торган төшенчәләр һәм билгеләмәләр:

Бюджеттан тыш акчалар – СЮКБО тарафыннан төрле чыганаклардан алынган акчалар, аларның барлыкка килүе һәм аларны файдалану Россия Федерациясе законнары һәм башка норматив хокукый актлары, шулай ук СЮКБОның (шул исәптән СЮКБОның үз акчалары) гамәлгә кую документлары белән билгеләнгән, федераль бюджеттан, Татарстан Республикасы республика бюджетыннан, «Яр Чаллы шәһәре» муниципаль берәмлеге бюджетыннан бирелгән акчалардан тыш.

Чара – нинди дә булса социаль әһәмияткә ия максатны гамәлгә ашыруга (тормышка ашыруга) юнәлдерелгән оештырылган гамәл яки гамәлләр җыелмасы.

Социаль әһәмияткә ия максат – нәтиҗәсе социаль проблемаларны хәл итүгә, гражданлык җәмгыятен үстерүгә юнәлдерелгән максат.

СЮКБОның максатчан төркеме - Россия Федерациясе законнарында каралган һәм СЮКБОның гамәлгә кую документлары белән билгеләнгән гражданнар категорияләре җыелмасы, күрсәтелгән СЮКБО аларга карата, гамәлгә кую документлары нигезендә «Коммерцияле булмаган оешмалар турында» 1996 елның 12 гыйнварындагы 7-ФЗ номерлы Федераль законның 31.1 статьясындагы 1 пунктында күрсәтелгән эшчәнлек төрләрен гамәлгә ашыра.

Башка терминнар һәм төшенчәләр әлеге Тәртип кысаларында Россия Федерациясенең гамәлдәге законнары белән билгеләнгән мәгънәдә кулланыла.

3. СЮКБО эшчәнлегенә анализ Яр Чаллы шәһәре муниципаль мөлкәткә түләүсез файдалануга яисә ташламалы шартларда арендага бирелгән социаль юнәлешле коммерцияле булмаган оешмаларга карата үткәрелә.

4. СЮКБО эшчәнлеген анализ үткәрү нәтиҗәләре Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегендә СЮКБО үсешенә юнәлдерелгән чаралар күрүне нигезләүгә юнәлдерелгән.

5. СЮКБО эшчәнлегенә анализ ел саен үткәрелә (календарь хисап елы өчен).

6. СЮКБО эшчәнлеген анализлау түбәндәге мәгълүмат чыганаклары нигезендә үткәрелә:

1) календарь хисап елында СЮКБО эшчәнлеге турында анкета;

2) хисап елында бухгалтерлык балансы һәм акчаларны максатчан файдалану турында хисап;

3) Россия Федерациясе Юстиция министрлыгының «Коммерцияле булмаган оешмаларның Интернет челтәрендә эшчәнлек турында хисаплар һәм эшчәнлекне дәвам итүләре турында хәбәрләр урнаштыру тәртибе хакында» 2010 елның 7 октябрендәге 252

номерлы Приказы нигезендә, Россия Федерациясе Юстиция министрлыгының мәгълүмат порталында урнаштырылган СЮКБО хисабы;

4) Россия Федерациясенең гамәлдәге законнары белән тыелмаган башка мәгълүмат чыганаклары (шул исәптән Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегендә аларга ярдәм күрсәтү максатларында СЮКБО тарафыннан бирелгән мәгълүматлар).

7. СЮКБО бирелә торган мәгълүматның дөреслеге өчен Россия Федерациясенең гамәлдәге законнарында билгеләнгәнчә җаваплы.

## 2 бүлек. СЮКБО эшчәнлеген бәяләү критерийлары

8. СЮКБО эшчәнлеген анализлау критерийлары түбәндәге күрсәткечләр буенча билгеләнә:

1) СЮКБО эшчәнлегенең мөлкәти күрсәткечләре;
2) СЮКБО эшчәнлегенең финанс күрсәткечләре;
3) СЮКБО эшчәнлегенең мәгълүмати күрсәткечләре;
4) СЮКБО эшчәнлегенең социаль күрсәткечләре;
5) СЮКБО эшчәнлегенең икътисадый күрсәткечләре.

## 3 бүлек. СЮКБО эшчәнлегенең мөлкәти күрсәткечләре

9. СЮКБО эшчәнлегенең мөлкәти күрсәткечләре үз эченә ала:

1) СЮКБОның мөлкәти торышы;
2) СЮКБО тарафыннан муниципаль милеккә карата мәҗбүри түләүләр буенча йөкләмәләр үтәлү.

10. СЮКБОның мөлкәти хәле, түләүсез файдалануга, арендага бирелгән муниципаль мөлкәт (бина, корылма, төзелмә) һәм (яки) муниципаль мөлкәттән тыш башка мөлкәт булудан (булмаудан) чыгып анализлана.

11. СЮКБОның муниципаль мөлкәткә карата мәҗбүри түләүләр буенча йөкләмәләрен үтәве СЮКБОның әлеге оешмага билгеләнгән тәртиптә түләүсез файдалануга, арендага бирелгән муниципаль мөлкәткә карата мәҗбүри түләүләр буенча бурычлары булудан (булмаудан) чыгып анализлана.

## 4 бүлек. СЮКБО эшчәнлегенең финанс күрсәткечләре

12. СЮКБО эшчәнлегенең финанс күрсәткечләре үз эченә ала:

1) СЮКБОның финанс тотрыклылыгы;
2) СЮКБОның финанс активлыгы;
3) СЮКБО чараларын бюджеттан тыш акчалар хисабына тормышка ашыру.

13. СЮКБОның финанс тотрыклылыгы СЮКБОның үз эшчәнлеген финанслар белән тәэмин итүнең төрле чыганакларыннан файдалануыннан чыгып анализлана, атап әйткәндә:

- федераль бюджеттан, Татарстан Республикасы бюджетыннан, Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге бюджетыннан максатчан керемнәр (субсидияләр, грантлар һәм башкалар);
- физик затлардан керемнәр, шул исәптән әгъзалык взнослары;
- юридик затлардан керемнәр;
- Россия Федерациясенең гамәлдәге законнары белән тыелмаган башка чыганаклардан керемнәр;
- товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләр сатудан керемнәр.

14. СЮКБОның финанс активлыгы СЮКБОның Россия Федерациясе башкарма хакимияте органнары, Россия Федерациясе субъектлары, Яр Чаллы шәһәре муниципаль

берәмлеге тарафыннан оештырыла торган, тиешле бюджет акчаларын алу өчен сайлап алуларда, конкурсларда катнашуыннан чыгып анализлана.

15. СЮКБО чараларын бюджеттан тыш акчалар хисабына тормышка ашыру СЮКБОның бюджеттан тыш акчалар хисабына гамәлгә ашырылган чараларыннан чыгып анализлана.

5 бүлек. СЮКБО эшчәнлегенең мәгълүмати күрсәткечләре

16. Әлеге Тәртип кысаларында СЮКБО эшчәнлегенең мәгълүмати күрсәткечләренә СЮКБОның ачыклыгы һәм мәгълүматларының һәркем файдаланырлык булуы керә.

17. СЮКБОның ачыклыгы һәм мәгълүматларының һәркем файдаланырлык булуы массакүләм мәгълүмат чараларында, «Интернет» мәгълүмати-телекоммуникация челтәрендә СЮКБОның эшчәнлеге турында урнаштырылган мәгълүматтан чыгып анализлана (СЮКБОның эшмәкәрлек һәм керем китерүче башка эшчәнлеге турында мәгълүматтан тыш).

6 бүлек. СЮКБО эшчәнлегенең социаль күрсәткечләре

18. СЮКБО эшчәнлегенең социаль күрсәткечләре:
1) СЮКБОның социаль активлыгы;
2) СЮКБО эшчәнлегеннән канәгать булу;
3) СЮКБО тарафыннан гражданнарны тарту;
4) СЮКБО хезмәткәрләре саны;
5) СЮКБО чараларын ирекле ярдәмчеләр катнашында тормышка ашыру.

19. СЮКБОның социаль активлыгы Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге грантларына һәм бюджет акчаларына финанслана торган чараларда катнашучы максатчан төркем гражданнар санының әлеге максатчан төркем гражданнарының санына нисбәтеннән чыгып билгеләнә.

СЮКБОның социаль активлык коэффициенты түбәндәге формула буенча исәпләнә:

$$K_{ca} = \frac{\text{чараларда катнашкан максатчан төркем гражданнары саны}}{\text{әлеге максатчан төркем гражданнары саны}} \times 100\%,$$

монда Кса - СЮКБОның социаль активлык коэффициенты.

20. СЮКБО эшчәнлегеннән канәгать булу бирелгән муниципаль мөлкәттә эшчәнлек алып барганда СЮКБО тарафыннан шартлар, максатлар үтәлүгә тикшерүләр үткәргәндә ачылган кимчелекләр, шулай ук СЮКБО эшчәнлегенә Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитетына (алга таба – Башкарма комитет) кергән нигезләнгән шикаятьләр булу белән билгеләнә.

21. СЮКБО тарафыннан гражданнарны тарту аларга карата СЮКБО чаралары тормышка ашырылган гражданнар саны белән билгеләнә.

22. СЮКБОның халык саны СЮКБО белән хезмәт мөнәсәбәтләрендә торучы гражданнар санынннан чыгып анализлана.

23. СЮКБО тарафыннан ирекләләр катнашында чараларны тормышка ашыру СЮКБО тарафыннан ирекләләр катнашында тормышка ашырылган чаралар санынннан чыгып анализлана.

7 бүлек. СЮКБО эшчәнлегенең икътисадый күрсәткече

24. Икътисадый күрсәткеч СЮКБО тарафыннан грантлар һәм бюджет акчаларын җәлеп итеп башкарылган чараларны тормышка ашыруга бүлеп бирелгән бюджеттан тыш акчалар күләменең СЮКБО чараларын тормышка ашыруның гомуми финанслау күләменә нисбәтеннән белән билгеләнә.

Икътисадый нәтиҗәлелек коэффициенты түбәндәге формула белән исәпләнә:

$$К_{ээ} = \frac{\sum_{i=1}^{n} Fв_i}{\sum_{i=1}^{n} Fo_i} \times 100\%, \text{ где:}$$

Кээ-СЮКБО эшчәнлегенең икътисадый нәтиҗәлелек коэффициенты;

Fвi -чараларны тормышка ашыруга СЮКБО тарафыннан бүлеп бирелгән бюджеттан тыш акчалар күләме;

Foi-СЮКБОны финанс белән тәэмин итүнең гомуми күләме.

8 бүлек. СЮКБО эшчәнлегенә анализ үткәрү тәртибе

25. Хисап елыннан соң килгән елның беренче апреленнән дә соңга калмыйча, СЮКБО ел саен Башкарма комитетның җир һәм мөлкәти мөнәсәбәтләр идарәсенә (алга таба - ҖММИ) җибәрә:

1) Тәртипкә 1 нче кушымтада каралган форма буенча календарь хисап елындагы эшчәнлеге турында анкета;

2) бухгалтерлык балансы;

3) хисап елында акчаларны максатчан файдалану турында хисап.

26. ҖММИ һәм Башкарма комитетның икътисадый үсеш һәм эшмәкәрлеккә ярдәм итү идарәсе (алга таба – икътисад идарәсе) хисап елыннан соң килгән елның беренче маена кадәр СЮКБО эшчәнлеге күрсәткечләрен формалаштыралар, Тәртипкә 2 нче кушымта нигезендә СЮКБО эшчәнлеген бәялиләр.

27. СЮКБО эшчәнлегенә үткәрелгән бәяләү нәтиҗәләре нигезендә ҖММИ, хисап елыннан соң килә торган елның беренче июненә кадәр, Башкарма комитет Җитәкчесенә СЮКБО эшчәнлеге, СЮКБО тарафыннан муниципаль мөлкәттән файдалану, СЮКБОга мөлкәти ярдәм күрсәтүне озайтуның максатка ярашлы булуы яки СЮКБО белән түләүсез файдалану шартнамәсен өзү турында мәгълүмат бирә.

Башкарма комитет Аппараты
Җитәкчесе урынбасары,
эш кәгазьләрен алып бару идарәсе башлыгы — Н.И. Галиева

Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегендә социаль юнәлешле коммерцияле булмаган оешмалар эшчәнлегенең финанс, икътисадый, социаль һәм башка күрсәткечләренә анализ үткәрү тәртибенә
1 нче кушымта

________ елда социаль юнәлешле коммерцияле булмаган оешманың эшчәнлеге турында анкета

1. СЮКБОның тулы һәм кыскартылган исеме:

______________________________________________

______________________________________________

2. СЮКБОга түләүсез файдалануга, арендага бирелгән муниципаль мөлкәт (бина, төзелмә, корылма) һәм (яки) муниципаль мөлкәттән тыш башкасы булу:

| | | |
|---|---|---|
| | муниципаль мөлкәте булу | ______________________ |
| | | (файдалану нигезе) |
| | башка мөлкәте булу | ______________________ |
| | | (файдалану нигезе) |
| | мөлкәте булмау | |

3. СЮКБО хезмәткәрләре саны (СЮКБО белән хезмәт мөнәсәбәтләрендә торучы гражданнар саны) (санын күрсәтергә) ________________.

4. СЮКБО эшчәнлеген финанслар белән тәэмин итү чыганаклары:

| № тб | Исеме | Керемнәр суммасы сум |
|---|---|---|
| 1 | максатчан керемнәр (субсидия, грантлар һ.б.) | |
| 2 | федераль бюджеттан керемнәр | |
| 3 | республика бюджетыннан керемнәр | |
| 4 | Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге бюджетыннан керемнәр | |
| 5 | физик затлардан керемнәр, шул исәптән әгъзалык взнослары | |

| | | |
|---|---|---|
| 6 | юридик затлардан керемнәр | |
| 7 | башка чыганаклардан керемнәр | |
| 8 | товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләр сатудан керемнәр. | |

5. СЮКБО чараларын бюджеттан тыш акчалар (СЮКБО тарафыннан төрле чыганаклардан алынган, шул исәптән СЮКБОның үз акчалары) исәбенә тормышка ашыру, СЮКБОга бирелгән грантлар һәм бюджет акчаларыннан тыш (җавап вариантын сайлагыз):

| | |
|---|---|
| | әйе |
| | юк |

6. Исемнәрен күрсәтеп, СОНКО тарафыннан тормышка ашырылган чараларның гомуми саны

______________________________________________

______________________________________________

______________________________________________

______________________________________________

______________________________________________

______________________________________________

7. СЮКБОның тиешле бюджет акчаларын алу өчен Россия Федерациясе башкарма хакимияте органнары, Россия Федерациясе субъектлары, Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге тарафыннан оештырыла торган сайлап алуларда, конкурсларда катнашуы:

| | |
|---|---|
| | әйе ______________________________ |
| | (сайлап алуның, конкурсның исеме, заявкалар (гаризалар) саны |
| | юк |

8. СЮКБОга грантлар һәм субсидияләр бирү:

| | |
|---|---|
| | әйе ______________________________ |
| | (субсидиянең исеме) |
| | юк |

9. Массакүләм мәгълүмат чараларында, «Интернет» мәгълүмати-телекоммуникация челтәрендә СЮКБОның эшчәнлеге турында урнаштырылган мәгълүмат булу

(СЮКБОның эшмәкәрлек һәм керем китерүче башка эшчәнлеге турында мәгълүматтан тыш):

| | |
|---|---|
| | әйе<br>__________________________________________________ |
| __________________________________________________<br>__________________________________________________<br>__________________________________________________ | |
| (чыганакның исеме, мәгълүматны урнаштыру датасы) | |
| | юк |

10. Аларга карата СЮКБО чаралары тормышка ашырылган гражданнар саны:

| | |
|---|---|
| | 50 гражданга кадәр; |
| | 50 дән 100 гә кадәр (100 кертеп); |
| | 101 дән 200 гә кадәр (200 кертеп); |
| | 201 дән 500 гә кадәр (500 кертеп); |
| | 500 гражданнан артык |

Әлеге анкетаны тутырганда

| |
|---|
| ________________________________________<br>(СЮКБО исемен күрсәтергә) |

эшчәнлеге турында __________________ календарь хисап елына мәгълүмат бирелгән.

Эшчәнлек турында мәгълүмат ирекле рәвештә бирелгән. Бирү датасына мәгълүмат актуаль булып тора.

| |
|---|
| ________________________________________<br>(СЮКБО исемен күрсәтергә) |

бирелгән мәгълүматларның дөреслеге өчен Россия Федерациясенең гамәлдәге законнары нигезендә җаваплы.

| | | |
|---|---|---|
| ________________<br>(вазыйфа) | ________________<br>(Ф.И.А.и.) | ________________<br>(имза) |
| | | "____" _______________ 20__ ел |

Анкетаны кабул итте:

| | | |
|---|---|---|
| ________________<br>(вазыйфа) | ________________<br>(Ф.И.А.и.) | ________________<br>(имза) |
| | | "____" _______________ 20__ ел |

Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегендә социаль юнәлешле коммерцияле булмаган оешмалар эшчәнлегенең финанс, икътисадый, социаль һәм башка күрсәткечләренә анализ үткәрү тәртибенә
2 нче кушымта

СЮКБО эшчәнлеге күрсәткечләрен бәяләү критерийлары

| № т/б | СЮКБО эшчәнлеге күрсәткече | СЮКБО эшчәнлеге күрсәткече характеристика | СЮКБО эшчәнлеге күрсәткечләрен бәяләү критерийлары (баллар) |
|---|---|---|---|
| 1. СЮКБО эшчәнлегенең мөлкәти күрсәткечләре | | | |
| 1.1. | СЮКБОның мөлкәти хәле | СЮКБОның түләүсез файдалануга, арендага бирелгән муниципаль мөлкәте (бина, корылма, төзелмә) һәм (яки) муниципаль мөлкәттән тыш башка мөлкәте булу (булмау) | муниципаль яки башка мөлкәте булу – 2 |
| | | | муниципаль яки башка мөлкәте булу – 1 |
| | | | мөлкәте юк – 0 |
| 1.2. | СЮКБО тарафыннан муниципаль мөлкәткә карата мәҗбүри түләүләр буенча йөкләмәләр үтәлү | СЮКБОның әлеге оешмага түләүсез билгеләнгән тәртиптә файдалануга, арендага бирелгән муниципаль мөлкәт өчен мәҗбүри түләүләр буенча бурычы булу (булмау) | бурычы бар– 0 |
| | | | бурычы юк – 1 |
| 2. СЮКБО эшчәнлегенең финанс күрсәткечләре | | | |
| 2.1. | СЮКБОның финанс тотрыклылыгы | СЮКБОның үз эшчәнлеген финанслар белән тәэмин итү өчен төрле чыганаклардан файдалануы | СЮКБОның финанслар белән тәэмин итү өчен өч чыганактан файдалануы – 3<br><br>СЮКБОның финанслар белән тәэмин итү өчен ике чыганактан файдалануы – 2 |
| | | | СЮКБОның финанслар белән тәэмин итү өчен бер чыганактан файдалануы – 1 |
| | | | финанслар белән тәэмин итү чыганаклары юк– 0 |

| | | | |
|---|---|---|---|
| 2.2. | СЮКБОның финанс активлыгы | СЮКБОның Россия Федерациясе башкарма хакимияте органнары, Россия Федерациясе субъектлары, Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге тарафыннан оештырыла торган, тиешле бюджет акчаларын алу өчен сайлап алуларда, конкурсларда катнашуы | әйе – 1 |
| | | | юк – 0 |
| 2.3. | СЮКБО чараларын бюджеттан тыш акчалар хисабына тормышка ашыру | СЮКБОның бюджеттан тыш акчалар, шул исәптән СЮКБОның үз акчасы хисабына тормышка ашырылган чаралары булу | әйе– 1 |
| | | | юк – 0 |
| | 3. СЮКБО эшчәнлегенең мәгълүмати күрсәткечләре | | |
| 3.1. | СЮКБОның ачыклыгы, халыкныкы һәм аның мәгълүматларыннан һәркем файдаланырлык булуы | Массакүләм мәгълүмат чараларында, «Интернет» мәгълүмати-телекоммуникация челтәрендә СЮКБОның эшчәнлеге турында урнаштырылган мәгълүмат булу (СЮКБОның эшмәкәрлек һәм керем китерүче башка эшчәнлеге турында мәгълүматтан тыш) | Бастырып чыгарылган материаллар юк – 0 |
| | | | 1 дән 5 кә кадәр материал бастырып чыгарылган– 1 |
| | | | 6 дан 10 га кадәр материал бастырып чыгарылган – 2 |
| | | | 10 нан артык – 3 |
| | 4. СЮКБО эшчәнлегенең социаль күрсәткечләре | | |
| 4.1. | СЮКБОның социаль активлыгы | Грантлар һәм бюджет акчаларына финанслана торган чараларда катнашучы максатчан төркем гражданнар санының әлеге максатчан төркем гражданнарының санына нисбәте (Кса - социаль активлык коэффициенты) | Кса 2% кадәр – 1 |
| | | | Кса 3% тән 5% кадәр – 2 |
| | | | Кса 6% дан 10% кадәр - 3 |
| | | | Кса 11% артык - 4 |

| | | | |
|---|---|---|---|
| 4.2. | СЮКБО эшчәнлегеннән канәгать булу | Бирелгән муниципаль мөлкәттә эшчәнлек алып барганда СЮКБО тарафыннан шартлар, максатлар үтәлүгә тикшерүләр үткәргәндә ачылган кимчелекләр, шулай ук СЮКБО эшчәнлегенә Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитетына (алга таба – Башкарма комитет) кергән нигезләнгән шикаятьләр булу | әйе - 0 |
| | | | юк – 1 |
| 4.3. | СЮКБОга гражданнарны тарту | Аларга карата СЮКБО чаралары тормышка ашырылган гражданнар саны | 50 гражданга кадәр – 1 |
| | | | 50 дән 100 гә кадәр граждан - 2 |
| | | | 101 дән 200 гә кадәр граждан - 3 |
| | | | 201 дән 500 гә кадәр граждан – 4 |
| | | | 500 гражданнан артык – 5 |
| 4.4. | СЮКБО хезмәткәрләре саны | СЮКБО белән хезмәт мөнәсәбәтләрендә торучы гражданнар саны | СЮКБО хезмәткәрләренең саны 5 кешегә кадәр- 1 |
| | | | СЮКБО хезмәткәрләренең саны 5 тән 10 кешегә кадәр - 2 |
| 4.5. | СЮКБО чараларын ирекле ярдәмчеләр катнашында тормышка ашыру | СЮКБО тарафыннан ирекләләр катнашында тормышка ашырылган чаралар саны | Чаралар булмау– 0 |
| | | | 1 дән 5 кәдәр чара - 1 |
| | | | 6 дан 10 кадәр чара - 2 |
| | | | 10 артык чара – 3 |
| 5. СЮКБО эшчәнлегенең икътисадый күрсәткече | | | |
| 5. | СЮКБО эшчәнлегенең икътисадый күрсәткече | СЮКБО тарафыннан грантлар һәм бюджет акчаларын җәлеп итеп башкарылган чараларны тормышка ашыруга бүлеп бирелгән бюджеттан тыш акчалар күләменең СЮКБО чараларын тормышка ашыруның гомуми финанслау күләменә нисбәте (Кээ - СЮКБО эшчәнлегенең икътисадый күрсәткече) | бюджеттан тыш акчалар булмау– 0 |
| | | | Кээ 20% кимрәк- 1 |
| | | | Кээ 20 дән 49% кадәр – 2 |
| | | | Кээ 50% артык - 3 |